Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№9 (60)

28 март 2013 ел

## • Универ хәлләре

**20 МАРТ КӨННЕ** Филология һәм сәнгать институтының татар филологиясе бүлегендә Татарстан Республикасының халык шагыйре, Г.Тукай ис. Дәүләт премиясе лауреты, М.Җәлил, А.Алиш ис. республика премияләре, халыкара Г.Х.Андерсен ис. әдәби бүләк иясе **РОБЕРТ МИҢНУЛЛИНГА БАГЫШЛАНГАН КИЧӘ** узды. Чара шагыйрьнең 65 яшьлек юбилее уңаеннан оештырылган.

• • • •

**24 МАРТТА** КФУның Тарих институтында мәктәп укучылары катнашында Татарстан Республикасы һәм татар халкы тарихына багышланган **РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ** узды.

• • • •

**25 МАРТТ**а ректор **И.ГАФУРОВ** җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**.

Административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.Хашов** контроль йөкләмәләрнең үтәлеше һәм КФУда якын арада булачак чаралар турында мәгълүмат бирде.

Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты директоры **Н.Мөхәррәмов** институтның Үсеш программасын тәкъдир итте. Ул төп максат-бурычлар, институтның тикшеренү өлкәләре белән таныштырды, структур бүленешнең көчле һәм йомшак якларын билгеләп узды, аның чит ил һәм Россия югары уку йортлары белән хезмәттәшлек итүе турында сөйләде. **Н.Мөхәррәмов** фикеренчә, тәҗрибәле журналистның, кагыйдә буларак, фәнни дәрәҗәсе булмый, чөнки уку йортында мондый белгечләргә түләү дәрәҗәсе аларны кызыксындырырлык түгел. Ректор әлеге мәсьәләнең чишелеш юлларын эзләргә тәкъдим итте.

Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе **С.Ионенко** кабул итү кампаниясенә әзерлек барышы, 2012/2013 уку елларында Казан федераль университетының профориентация эше нәтиҗәләре белән таныштырды.

Фәнни эшчәнлек буенча проректор **Д.Нургалиев** КФУның Кайгыртучанлык советы стипендиясенә лаек булган яшь галимнәр исемлеге белән таныштырды һәм КФУ делегациясенең Чехия Республикасына ясаган визиты турында сөйләде. Тышкы багланышлар буенча проректор **Л.Латыйпов** исә, Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтының Төркиягә визиты хакындагы хәбәр белән чыгыш ясады.

Тышкы багланышлар Департаменты директоры **А.Крылов** ТР Хөкүмәтенең «Алгарыш» грантын алу өчен яңа программасы ачылу турында игълан итте. Утырыш ахырында И.Гафуров институтларны Кайгыртучанлык советы белән тыгыз бәйләнештә торырга чакырды. Ул шулай ук университетта хәйрия фондын оештыру тәкъдиме белән чыкты.

• • • •

**25 МАРТТА** Казан федераль университетының **3HARD КОМАНДАСЫ** Voxel Sculptor проектында катнашып, **III УРЫН** яулады. КФУ студентлары Kinnect сенсоры ярдәмендә өч катлы объектларны модельләштерү ысулын тәкъдим итте. Әлеге проект «Инновацияләр» номинациясендә иң яхшы эш дип табылды.

• • • •

**26 МАРТ** көнне КФУда **«ПРОФЕССОР А.П.МИЩЕНКО ИСЕМЕНДӘГЕ ФӘННИ УКУЛАР»** дип исемләнгән **БӨТЕНРОССИЯ ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ** узды. Шул ук көнне маркетинг буенча **ОЛИМПИАДА** булды. Бирегә Россиянең төрле шәһәрләреннән килгән егермедән артык команда катнашты.

• • • •

ТР студентлары һәм укучылары арасында уздырылган программалаштыру буенча XIII ачык командалы турнирда **ХИСАПЛАУ МАТЕМАТИКАСЫ** һәм **МӘГЪЛҮМАТИ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ИНСТИТУТЫ СТУДЕНТЛАРЫ III ДӘРӘҖӘДӘГЕ ДИПЛОМГА ЛАЕК** дип табылды.

• • • •

**27 МАРТТАН 29 МАРТКА** кадәр **УНИВЕРСИТЕТТА** Гиссен университеты профессоры, доктор **МИХАЭЛЬ ШМИТЦ** булачак. Ул 2013/2014 елга студентлар алмашу программасы кысаларында студентлар сайлаячак. Визит вакытында профессор белән төрле очрашулар да узачак.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*










Алия Галимуллина фотолары

# Сан сыйфатка күчсен

Динара **МИННЕКАЕВА**,
хәбәрче

27 март көнне КФУның чираттагы Гыйльми советы узды. Анда 2012 елгы эшчәнлеккә нәтиҗә ясалды һәм киләчәккә планнар каралды.

Утырыш башланганчы, ректор Илшат Гафуров уку йортыбыз хезмәткәрләренә, ирешелгән уңышлары белән котлап, төрле дәрәҗәдәге бүләкләр тапшырды. Беренче булып, биология фәннәре докторы, Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институтының сәламәтлекне саклау һәм физиология, анатомия кафедрасы галимәсе Татьяна Аникина профессор аттестатына ия булды.

«РФнең югары белем бирү өлкәсендәге мактаулы хезмәткәре» дигән дәрәҗәле исемнәр Педагогика һәм психология институты директорының фәнни эшләр буенча урынбасары Владислав Виноградовка, Н.И.Лобачевский ис. Математика һәм механика институтының дифференциаль тигезләмәләр кафедрасы доценты Сергей Киясовка, юридик факультетның җинаять процессы һәм криминалистика кафедрасы доценты Валерий Романовка, Фундаменталь медицина һәм биология институтының ботаника кафедрасы доценты Андрей Ситниковка, Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институтының гамәли математика кафедрасы доценты Игорь Филипповка, Филология һәм сәнгать институтының сәнгать теориясе һәм мәдәният кафедрасы җитәкчесе Зилия Явгильдинага бирелде.

Ректор шулай ук фундаменталь тикшеренүләр башкаруда зур уңышларга ирешкән хезмәткәрләргә дә сертификатлар тапшырды. Менә алар: Борис Малкин – Физика институтының теоретик физика кафедрасы профессоры, Михаил Варфоломеев – А.М.Бутлеров ис. Химия институтының физик химия кафедрасы доценты, Равил Фәхруллин – Фундаменталь медицина һәм биология институтының микробилогия кафедрасы доценты.

«Россия дәүләт вузларының яшь укытучылары грантлары» конкурсында җиңү яулаганы өчен, Потанин ис. Хәйрия фонды дипломы Физика институтының оптика һәм нанофотоника кафедрасы ассистенты Мансур Сибгатуллинга тапшырылды.

Көн тәртибенә куелган мәсьәләләргә күчкәнче, Илшат Гафуров агымдагы проблемаларга тукталды. «Без заман шартларына туры килерлек итеп эшләргә тиеш. Эшләү өчен шартлар юк, дип әйтеп булмый. Шушы көннәрдә Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты белән танышып чыктым. Ошамаган әйберләр дә бар. Университет – уку йорты. Сүз дә юк, тарихи шәхесләребезне мәңгеләштерергә кирәк, ләкин музейлар ачып түгел. Әйтик, күренекле галимнәребезнең исеме белән лабораторияләрне атарга, стенага фотоларын эләргә була», – диде. Аспирантура буенча да кайбер фикерләре белән уртаклашты.

## • Бездә кунак бар

# КФУга өметләр зур!

Дания **ФАТЫЙХОВА**,
хәбәрче

27 март көнне Казан федераль университетына РФнең К.Корея Илчелеге каршындагы Корея милли фондыннан директор Хве-гил Ким әфәнде җитәкчелегендәге делегация визит ясады. Чара Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтының Корея үзәгендә узды. Визит кысаларында кунаклар ачык дәрес карадылар.

Ахыры 2нче биттә.



Алия Галимуллина фотосы

# Сан сыйфатка күчсен

Башы 1нче биттә.

Ректор фикеренчә, түләү нигезендә укырга алынган аспирантларны уку йортына эшкә алырга, стипендия бирергә, торак белән тәэмин итәргә була.

Беренче көн тәртибе кысаларында, Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин Совет әгъзаларын КФУның 2012 елгы Үсеш Прогограммасы нәтиҗәләре һәм 2013 елга планнар белән таныштырды. Ул структур бүлекчәләрнең рейтингына тукталды. Ректор, алар белән танышкач, нәтиҗәләрне яңадан тикшерергә кушты. Аның фикеренчә, рейтингта беренче урында торган институтларның эшләгән эшләре, уңышларының нәтиҗәсе тиешле дәрәҗәдә күренми.

2012 елдагы фәнни-тикшеренү эшләре нәтиҗәләре буенча Фәнни эшчәнлек буенча проректор Данис Нургалиев хисап тотты. Хезмәткәрләрнең югары дәрәҗәле басмаларда дөнья күргән мәкаләләре, яклаган һәм якламаган аспирантлар саны, безнең уку йортының фән буенча дөнья күләмендә токан урыны белән таныштырды. Бу юнәлештә филолог һәм биологларның күрсәткечләре яхшы. Соңгы елда фәнни-тикшеренү эшчәнлеген оештыру рейтингы кимегән, нәтиҗәлелек, киресенчә, арткан. Татарстандагы башка уку йортлары белән чагыштырганда, басылып чыгу да активлыгы алдынгы рәттә тора, Россия күләмендә исә, без бишенче урында. Бу уңайдан ректор алга таба тагын да активрак булырга чакырды. «Шушы нәтиҗәләргә карап, бюджет урыннары да бүлеп биреләчәк. Күрсәткечләр түбән төшәргә тиеш түгел, аларны арттыру өчен тырышырга кирәк», – диде.

Гыйльми советта шулай ук кафедра җитәкчеләрен сайлау, гыйльми дәрәҗәләргә тәкъдим итү булды һәм башка төрле мәсьәләләр каралды.

● Белем баскычлары

# Озын юлның башында

Алинә САДЫЙКОВА, хәбәрче

Укытучы кеше галим булып өлгерсен өчен ниләр кирәк? Күпләр тирән акыл, киң белем, үз фәнен биш бармагы кебек белү дип җавап бирер. Ә бәлки, тагын берәр нәрсә кирәктер? КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институты галиме Людмила Леонидовна Фролова бу сорауга: «Яхшы команда кирәк», – дип җавап бирде.



**✦ Белешмә**
«Who is who in the world» – дөнья күләмендә танылган, ниндидер өлкәдә уңыш казанган шәхесләрнең биографияләрен бастыра торган җыентык. Аңа рәссам, композитор, галим, бизнесмен һәм башкалар кертелергә мөмкин. Елга бер чыгарыла торган басманың быел утызынчы юбилей саны. Әлеге җыентыкның төп максаты – прогрессив, алдынгы карашлы, стандарт булмаган кешеләрне дөньяга таныту.

Бүгенге көндә Людмила Фролова – Фундаменталь медицина һәм биология институты, фундаменталь медицина бүлегенең генетика кафедрасы доценты. «Бу ел – минем өчен бик истәлекле һәм мөһим ел. Университетта эшли башлавыма чирек гасыр була», – дип елмаеп куйды галимә. Шулай да, 2013 ел аның өчен бүтән яклары белән дә истә калачак. Чөнки күптән түгел чыккан «Who is who in the world» басмасында аның биографиясе урын алган.

Людмила Фролова әйтүенчә, «Who is who in the world» – ул кешенең танылу дәрәҗәсен күрсәтә торган индикатор. Аңа җиңел генә эләгеп булмый. Бу эш, гадәттә, башка галимнәр рекомендациясе белән башкарыла. Мәгълүматлар, кат-кат тикшерелеп, иләк аша узганнан соң гына, басмада урын ала. Людмила Фролованы Россиядә генә түгел, чит илдә дә яхшы беләләр. Галимә су һәм туфракны саклау халыкара ассоциациясендә инде 3 ел дәвамында Россиянең милли вәкиле булып тора. Артык тыйнак галимә 3 тапкыр чакырганнан соң гына басылырга ризалык бирә: «Бу бик күңелле вакыйга, чөнки Россиянең һәр гражданинына да шундый югары престижлы җыентыкка керү бәхете елмаймый. Бу – минем хезмәтемә, фәнни карьерама югары бәя нәтиҗәсе. Монда ниндидер закончалык күзәтелә».

Нинди казанышлары өчен Людмила Фролова шундый югары бәя алган соң? Баштарак ул экология факультеты студентларын гыйлемле итүгә көч куйган булса, хәзер инде Фундаменталь медицина һәм биология институты студентларына фән серләрен өйрәтә. Хәзерге көндә алып бара торган эшчәнлеге экология һәм молекуляр генетика фәннәре киселешендә тора. Бу юнәлеш әле яңа булып санала һәм галимәгә әлеге эшендә үзенең командасы ярдәмгә килә. Команда дигәндә, алар шул институтның яшь галимнәре – 3 курс студентлары Алинә Низаметдинова, Эльмира Шагабиева, Лиза Сазанова. Алар, остазлары белән бергәләп, үзгәрә торган ситуацияләргә геннарның җавап кайтаруын өйрәнәләр. «Без инде бик күп геннарны тикшерсәк, байтак кына эшләсәк тә, олы юлның башында гына әле!» – дип билгеләп үтте галимә. Алар әйләнә-тирәнең үзгәрүе өчен җавап бирә торган геннар эзләгәннәр. Алинә Низамутдинова CO-1, Эльмира Шагабиева Cytochrom b, Actim mRNA, Лиза Сазанова Histon $H_3$, factor 1-alpha геннары белән эш иткәннәр. Быел исә, команда аминокислоталы эзлеклелек, ягъни аксымга күчкән. «Без икенче, яңа дәрәҗә тикшеренүләргә күчтек. Бу бик авыр эш һәм аның турында мәгълүмат та бик аз. Шундый кыенлыкларга карамастан, кызларым биоинформатикадан курыкмадылар. Аларның эшләргә теләкләре булды һәм инде хәзер без бу темага сөйләшүләрне тигез хокукта алып бара алабыз. Алар эшнең очына чыга алдылар. Бу, иң беренче чиратта, минем өчен бик мөһим. Мин алар белән горурланам!» – дип мактады укучыларын Людмила Леонидовна. Эльмира Шагабиева исә: «Без бөтен эшне бергә эшлибез. Командада эшләве җиңелрәк. Шундый остазыбыз, дусларым булганда күп нәрсәгә ирешеп була», – дип тә өстәп куйды. Команданың алга таба планнары бик зур: ясаган ачышлары нәтиҗәсен гамәлгә ашырырга телиләр. Алар инде эш тәртибен беләләр, юнәлеш бирергә остазлары бар. Гаҗәп тә түгел: шундый яхшы атмосферада эшлисе генә килеп тора. Алар бер гаилә сыман: дус-тату, ярдәмчел, сокланмый мөмкин түгел. Аларга алга таба күп ачышлар, уңышлы проектлар телибез.

● Бездә кунак бар

# КФУга өметләр зур!

Башы 1нче биттә.

Корея үзәге Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтында 2007 елның сентябрь аенда формалаша. Россиядәге Корея фонды эшчәнлеге Мәскәү, Санкт-Петербург, Владивосток университетларында гына түгел, Казан федераль университетында да корея телен тирәнтен өйрәнү мөмкинлеге бирә. Укыту заманча таләпләргә туры килә торган стандартларга нигезләнеп алып барыла: Корея фонды студентларны мультимедиа материаллары, кирәкле китаплар, видеоязмалар белән тәэмин итеп тора. Әлеге әсбаплар Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты студентларына дәрестән тыш уку, өйрәнү өчен бирелә. Гадәти дәресләр белән беррәттән, студентлар Кореянең дине, мәдәнияте, тарихы, фәлсәфәсе буенча лекцияләр тыңлыйлар.



Бүгенге көндә КФУның Корея республикасы университетлары (Сеул университеты, Корё университеты, Чхонджу университеты, Кукмин университеты һәм Инчхон университеты) белән хезмәттәшлек итү ниятенә туры килә торган 5 килешү бар. Чхонджу университеты, Кукмин университеты белән хезмәттәшлек итү һәм студентлар алмашу программалары гамәлгә ашырыла.

«Безнең бүгенге визитыбызның максаты: укытучыларның укыту процессын, дәресне ничек алып баруын карау. Шул күзәтүләрдән чыгып, бу процессны камилләштерү юлларын эзләүне дәвам итәбез. Без Казан федераль университетына зур өметләр баглыйбыз. Билгеле, монда иҗтимагый нечкәлекләр дә бар. Шуңа күрә, безгә һәр якны истә тотарга, гамәлләребезне нигезле, сыйфатлы башкарырга кирәк», – дип белдерде Хве-гил Ким әфәнде.

*Алия Галимуллина фотолары*



● Җуелмас байлык

# Беренче физика аудиториясе

Төп бинаның йөзек ташы санала торган беренче физика аудиториясе үзенең барлыкка килүе белән архитектор К.Л.Мюфкега бурычлы. Мюфке архитектор П.Г.Пятницкийның төзегән, ул вакытка шактый таушалган бер катлы көнбатыш флигельне сүтеп, аның урынына өр-яңа өч катлы корпус төзи. Бу корылма үз эченә берничә зур аудитория, лаборатория бүлмәсе һәм кабинетларны сыйдыра. Ул төп бинага галерея белән тоташкан. Галерея исә үтеп йөрелмәле залны, икенче һәм өченче кат биеклегендәге зиннәтле амфитеатры, арткы өлешендә балконы һәм дәү аркалы тәрәзләре булган аудитория белән тоташтыра. Ә түшәм һәм алгы як дивар кулдан ясалган нәфис детальләр белән бизәлгән.



# Актлар залы

Университетның актлар залы 1825 елның җәендә ачыла. Н.И.Лобачевский ректор вазифасына керешкәндә, нәкъ менә биредә патшага, туган илгә, фәнгә һәм университетка намус һәм риясызлык белән хезмәт итәргә ант итә.

Бүген актлар залы – Университетта оештырыла торган төп бәйрәм чараларының уздырылу урыны. Кергәч тә, каршы як диварда Университетка нигез салган Александр I портреты эленеп тора. Портрет 1806 елда Петербург рәссамы – академик Рацетти тарафыннан ясалган. Рәссам яшь императорны Казан Император Университетын Раслау грамотасына кул куйган вакытында сурәтләгән. Сул як диварда исә, Университетның күренекле галимнәре һәм шәкертләре – С.Т.Аксаков, А.М.Бутлеров, Н.И.Лобачевский, Л.Н.Толстой, А.П.Щапов портретлары.



• Сәнгать

# Музыкага гашыйк юрист

Динә МӨХТӘСИПОВА,
хәбәрче

XX гасыр башында халык традицияләренең Аурупа классик музыкасы иҗат чаралары белән кушылуына нигезләнгән заманча милли профессиональ татар музыкасы формалаша, композиторлар, җыр, музыка башкаручылар дәртләнеп иҗат итә башлыйлар. Композитор, педагог, фольклорчы, җәмәгать эшлеклесе Солтан Габәшинең музыкаль сәләте шул катлаулы чорда чәчәк ата. Ул, татар театры тарихында беренче буларак, спектакль өчен махсус музыка иҗат итә.



Солтан Хәсән улы Габәши 1891 елның 1 маенда элеккеге Казан губернасы Сулабаш авылында (хәзерге Биектау районы) туа. Габәши кечкенә вакытында ук кубызда, гармунда халык көйләрен уйнарга өйрәнә. Гаиләләре белән Уфага күчеп килгәч, үзлегеннән фортепьянода уйный башлый. Бу турыда искә алып, Габәши: «Ул вакытта мин музыка белән бернинди дә максат куймыйча, болай гына шөгыльләнә идем», – дип яза. Шулай булуга карамастан, бу вакытта алган белеме аңа музыка дөньясына керер китүгә юл ача, ә соңга табарак инде ул бөтен тормышын музыкаль эшчәнлеккә багышлый. 1909 елдан әдәби музыкаль кичәләрдә, татар музыкасы концертларында катнаша башлый, пианист-аккомпаниатор буларак чыгышлар ясый. Мәктәпләрдә дәресләр алып бара. Әкренләп, үзендә дә көйләр язып карау теләге туа.

1915 елда музыкага бөтен җаны белән гашыйк С. Габәши Казанга кайта һәм университетның юридик факультетына укырга керә. Ике ел укыгач, аны армиягә алалар. Казанда аның музыка буенча эшчәнлеге тагын да активлаша. С.Габәши татар драма труппасының берничә спектакленә (Г.Исхакыйның «Зөләйха», Ф.Бурнашның «Таһир-Зөһрә», К.Рәхимнең «Бүз егет» әсәрләре) музыка яза. Актуаль темага язылган җырлары, «Яңалиф маршы» үз вакытында халыкка киң таныла. Композиторның «Кәккүк» романсы – шулай ук халык мәхәббәтен яулаган әсәрләренең берсе.

20 елларда Татарстанда татарча профессиональ музыка белеме бирү башлана. С.Габәши музыка белеме бирүче беренче укытучылар сафында була: хор дәресе, музыка теориясе буенча укыта. Казан музыка техникумы директоры урынбасары булып эшли. Татарстан районнарына фольклор экспедицияләренә чыга.

Республикабыз музыка сәнгате өчен бөтенләй яңа булган хор сәнгатенең үсешенә С.Габәши аеруча зур өлеш кертә. Шул максатны күздә тотып, ул татар халык җырларын катнаш хор белән башкару өчен эшкәртә. Әлеге әсәрләр яңа гына оешкан бик күп хор коллективларының төп репертуарын тәшкил итә.

Газиз Әлмөхәммәтов һәм Василий Виноградов белән берлектә, С.Габәши беренче татар опералары – «Сания» (1925) һәм «Эшче»не (1930) иҗат итүдә катнаша.

Композитор Солтан Габәшинең гөрләп үскән иҗат эшчәнлеге, скрипка кылы шартлап өзелгәч, кинәт тынган музыкадай, туктап кала. Моңа «Татар музыкасында Габәшичелеккә каршы» дигән мәкалә сәбәп була. Анда композиторның борынгы матур көйләргә мәхәббәте катып калганлык, искелеккә ябышып яту, милләтчелек, пантюркизм, панисламизм, дип бәяләнә. Солтан Габәши, Казанны калдырып, Уфага китәргә мәҗбүр була. Анда да ул музыка өлкәсендә армый-талмый эшли һәм «Сания», «Эшче» операларын кабат сәхнәләштерү турында хыяллана. Эзләп карасалар, Казанда ике операның да партитуралары, клавирлары юк, алар юк ителгән булып чыга. Бәхеткә, «Сания» операсы партитурасы – тулысынча, «Эшче»неке өлешчә Солтан Габәшинең үзендә калган була. Әмма беренче татар операларына сәхнәгә әйләнеп кайту насыйп булмый, чөнки Ватан сугышы башлана, ә Солтан Габәшине гаиләсе белән Башкортстанның караңгы бер авылына сөрәләр. Анда беренче профессиональ композиторыбыз мәктәптә гап-гади музыка укытучысы булып эшли. Күпме якты хыяллары тормышка ашмый, күпме матур музыкалар тумый кала. 1942 елда ул 51 яшендә вафат була.

• Тарих сәхифәләреннән




***1983:***

23 мартта Казан университетында «Социалистик җәмгыять шартларында дәүләт һәм хокук механизмын функцияләштерү» дигән фән юнәлеше буенча совет раслана.

***1993:***

26 мартта КДУ Югары Идел буе уку йортлары китапханәләренең зональ методика үзәге дип игълан ителә.

***2003:***

25 мартта РФ Фән һәм мәгариф министрының 1187 номерлы боерыгы белән, квалификацияле белгечләр әзерләүнең сыйфатын яхшырту һәм студентларда уку эшчәнлеге, булачак һөнәрләренә кызыксыну уяту максатында, Бөтенроссия студентлар олимпиадасын уздыру турындагы нигезләмә раслана.

28 мартта, Болгария республикасы белән фәнни хезмәттәшлекне ныгыту максатыннан, Казан университеты ректоры боерыгы белән, университетта Болгариянең Россиядәге вәкилләре катнашында чаралар уздыру турындагы программа раслана.

31 мартта КДУда 4 кафедраны үз эченә алган психология факультеты ачыла. «Журналистика, социология һәм психология факультеты» атамасы исә, «Журналистика һәм социология факультеты» дип үзгәртелә.

• Әдәп-әхлак

# «Әнем, урын бир әле...»

Илмир ВӘЛИЕВ,
Математика һәм механика институты

«Хөрмәтле пассажирлар, юл йөрү кагыйдәләрен төгәл үтәгез, бер-берегезгә ихтирамлы булыгыз. Өлкәннәргә, инвалидларга, балалы пассажирларга урын бирергә онытмагыз». Метро яки автобуста «күренми торган» апаның әлеге сүзләре бөтен кешегә дә таныштыр. Бу сүзләр көн саен һәр студент колагына кимендә ике тапкыр үтеп керә. Берсеннән керә, икенчесеннән шунда ук чыгып та китә шул...



Яшьләрнең шәһәр транспортында үзен тота белмәве, гомумән, әдәп-тәрбия кагыйдәләрен үтәмәүләреннән олы яшьтәге апа-абыйларның зарлануы яңалык түгел. Кайвакыт яшьтәшләремнең кыланышына үземнең дә ачуым килә. Безгә таныш бер күренешкә генә тукталыйк: университетка һәр көн «Универсиада авылы» яки «Академик Парин» тукталышларыннан меңләгән студент йөри. Аларның күпчелеге йокысын укырга барганда да, кайтканда да җәмәгать транспортында туйдыра. Әйе, без дә арыйбыз: уку, китапханә, баш эшкәртеп бетерә алмаслык мәгълүмат. Ләкин без әле яшь, үзебезне олылар урынына куеп карарга өйрәнмәгән. Бу проблема нәрсәгә бәйле? Балачакта алган тәрбиягәме, әллә инде барысына да үзебез генә гаеплеме?

Әдәпле кеше солтан, әдәпсезнең бите олтан, ди татар халык мәкале. Ләкин монда сүз үзен әллә кемгә куеп, баш булып утыручы солтан турында түгел, ә зур хөрмәткә ия, мәрхәмәтле кеше турында бара. Шундый солтан булырга һәммәбез дә омтылыйк. Бүгенге яшәеш һәм холкыбыз киләчәктә үзебезгә киресе белән әйләнеп кайтмасын иде.

**Өлкәннәр фикере:**

**Универсиада авылы мэры киңәшчесе Илгиз Абдулла улы Абдуллин:**

«Өлкәннәргә мәрхәмәтлелек проблемасы гомер-гомергә булган. Бер акыл иясе әйткән: илнең үсеш дәрәҗәсен шушы илдә яшәүчеләрнең өлкәннәргә карата мөнәсәбәтеннән билгеләргә була. Мин гомер буе җиңел машинада йөрдем, шуңа күрә халыкның шәһәр транспортында ничек җәфаланганын күрмәдем. Хәзер, автобус-метрода йөри башлагач, проблеманың тамыры бик тирәнгә киткәнен аңладым. Мине яшьләрнең гади генә нәрсәләрне аңламавы рәнҗетә. Җәмәгать транспортында бөтен урыннар студентлар белән тулган, ә өлкән буын кешеләре, 8 сәгать буе физик көч таләп итә торган эшләрдә эшләүчеләр, басып бара... Сез, студентлар, дәресләрдә берничәшәр сәгать утырасыз. Мин һәрчак күзәтәм: өйгә кайткач та, утырып яисә ятып торасыз. Автобуста да утырып барасыз. Ә бит хәрәкәтләнүнең аз булуы сәламәтлекне ныгытмый.

Бөтен яшьләрне дә начар, дип булмый. Әгәр студент миңа: «утырыгыз, абый», – дип урын бирсә, миңа рәхәт булып китә, шул сүзләре йөрәгемә май булып ята.

Яшьләрнең шулай игътибарсыз булуына китергән сәбәпләр шактый. Күп гаиләләрдә ата-аналарның үзләрен тәрбияләргә кирәк. Без акча колына әйләндек, балаларны урам тәрбияли. Бу проблеманы хәл итүгә багышланган гамәлләрне тормышка ашыра башларга кайчан да соң түгел. Мәсәлән, «Студенческая весна» фестивалендә «Өлкән буынга ихтирам» номинациясен кертеп җибәрергә һәм анда өлкәннәргә ихтирам күрсәткән студентлар яисә төркемнәрне билгеләргә була. Төрле социаль сайтларда, куратор сәгатьләрендә бу мәсьәлә үзәктә торырга тиеш. Казанда гына күпме ялгыз әби-бабайлар яши. Һәр төркем үзенә шефлыкка бер генә ялгыз өлкән буын кешесен алса да, нинди зур ярдәм, университетыбызга хөрмәт булыр иде. Без өлкәннәрне елына ике тапкыр гына искә алабыз: 1 октябрь һәм 9 май көннәрендә. Һәм шуның белән бетте...»

**Студентлар фикере:**

**Гөлинә Гайнуллина (Математика һәм механика институты):**

«Яшьләрнең бөтенесен дә бер калыпка салырга кирәкми. Ләкин соңгы арада яшьтәшләремнең кайбер кыланышлары үземне дә таң калдыра. Тик мин моны өлкәннәрнең тәрбия җимеше дип тә әйтер идем. Мәсәлән, әниләр – кечкенә балалары, әбиләр оныклары белән автобус-троллейбусларга керәләр дә буш урыннарга балаларын утырталар, ә үзләре алар янәшәсендә басып баралар. Моны үрнәк дип әйтеп булмый. Утыртмасыннар димим, тик алларына алып, бергәләп утырсалар яхшырак булыр иде. Балада бит миннән өлкән кеше басып барса да ярый дигән фикер туарга мөмкин. Димәк, гаеп ике якта да бар. Тик ни генә булмасын, берничә яшь кешенең мәрхәмәтсез кыланышы белән бәйләп, барысын да гаепләмәсеннәр иде. Күңелләре изгелектә һәм намуслары саф булган яшьләребез бар әле».

• Белми калма!

***29 март көнне КФУның Яр Чаллы институтында «МедиаПоколение» исемле IV Бөтенроссия балалар һәм яшүсмерләр массакүләм мәгълүмат чаралары фестивале булачак.*** *Чараны филология һәм журналистика факультеты оештыра. Фестиваль кысаларында биш төрле мастер-класс узачак. Фестивальнең йомгаклау турында безнең редакция хезмәткәрләре дә катнашачак.*

***

***30 март көнне Кече Филология һәм сәнгать институтының оешуына бер ел тулу уңаеннан, тантаналы чара узачак.*** *Бер ел гына эшләвенә карамастан, Кече институт үз нәтиҗәсен күрсәтергә өлгерде. Ул гуманитар фәннәр буенча сәләтле балаларны җәлеп итү максатын бик актив рәвештә тормышка ашыра.*

***

***КФУның Немец теле фәне һәм мәдәнияте үзәге, немец телен интенсив рәвештә өйрәнергә теләүчеләр өчен, җәйге мәктәп оештыра.*** *Бер ай (июнь, атнага 3 тапкыр) дүрт академ. сәгать дәвамында белем алганнарга Европа дәрәҗәсендәге сертификат тапшырылачак. Программа турында тулырак мәгълүматны 292 08 93 телефоны аша алып була.*

• Әдәби сәйләннәр



Таныш булыгыз: ижатташ дустыбыз – Айсылу Гайфуллина. 1993 елнын 24 августында Алабуга районы Морт авылында туган. Тәржемәче булу, күп илләргә барып, дөнья күрү, яна танышлар табу теләген тормышка ашыру өчен, Филология һәм сәнгать институтынын тәржемә бүлегенә укырга кергән. Киләчәктә үзен югары белемле, үз юлын дөрес билгеләгән белгеч итеп күрә. Шигырьләр дә язарга ярата. 11 сыйныфта укыганда, анын житәкчелегендә «Гаиләм – бәхетем» дигән газета чыккан.

# Язгы иртә

Иртән тәрәзәгә килсәң, уянып килә торган язгы табигатьнең хозурлыгына таң каласың. Язгы иртәнең рәхәтлеген тоясы килеп, күңелем мине урамга өнди.

Ишекне ачып, бер адым атлауга, борынга яз исе килеп керә. Бер кавым күземне йомып, шул ис белән ләззәтләнәм. Йомшак акрын җил, әниемнең назлы кулларыдай, чәчләремне сыйпап үтә. Язгы табигать белән бергә, күңелдә яңа хисләр, ниндидер бер җылы бөркеп торган рәхәтлек уяна. Офык артыннан күтәрелеп килгән кояшның алтын нурлары, һәр якка таралып, табигатьне җанландыра.

Эх, язгы иртә! Тыныч та, шул ук вакытта сихри һәм сокландыргыч та була беләсең. Табигатькә яңа тормыш өргән кебек, кешеләрнең дә күңелендә җыелып килгән «боз»ларын эретеп, яңа хыялларга, яңа өметләргә юл ачасың. Яшәрү вә куәтләнүгә дә син сәбәпчедер.



Язгы иртәнең рәхәтлегенә чумып, салмак кына атлыйм. Кошларның чыркылдаган авазлары колакны иркәли. Утраучык-утраучык булып калган карлар актык көннәрен саныйлар. Агачларга гына күз атыйк! Карлар эреп, җир дымга туенгач, аларның тамырлары киңәя. Дым, кәүсә буйлап өскә менеп, ботакларга таралганнан соң, яшел бөреләр бүртә. Әнә бит ул бөреләр! Озакламый алар, яфрак ярып, агачларны яшеллеккә күмәр. Юлларда гөрләвекләр кузгалырга әзер тора, төшкә таба, кояш югары күтәрелгәч, алар үзләренең хәрәкәтен башлый. Тереклек дөньясына да җан керә. Кыш буе күзгә чалынмаган бөҗәкләрнең хәзер ниндиен генә күрмәссең. Карасы дисеңме, коңгырты, сорысы – һәрберсе дә үз эше белән мәшгуль.

Юлымны дәвам итәм. Берәмберәм кешеләр дә очрый башлый. Яз миңа гына түгел, башкаларга да тәэсир итә, күрәсең. Кышкы авыр киемнәрдән арынып калган кешеләрнең йөрешендә ниндидер бер җиңеллек, очыну сизәргә мөмкин. Йөзләрендә язгы нур, елмаю, мөлаемлык урын ала. Алар да, нәкъ табигать кебек үк, үзгәрә, яшәрә. Табигатькә җан өреп, яз кеше күңеленә дә кереп урнаша.

Сөйләсәң, сөйләп туймаслык, сурәтләсәң, сурәтләп бетерә алмаслык ел фасылыдыр ул – яз!

• Универсиаданы каршылап

Казаныбыз хәзер Универсиаданы көтеп яши. Телевизорда да, газетада да күп мәгълүмат шул турыда. Универсиадага әзерлек шәһәребезгә күп санлы ремонтлар, бөкеләр, мәшәкатьләр белән бергә, сәламәт яшәү рәвешен дә алып килде. Спорт белән дуслашучылар саны көннән-көн арта. Шул исәптән, профессиональ спорт белән шөгыльләнүчеләр өчен дә бик зур мөмкинлекләр ачыла. Университетыбызның Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты студенты Ильяс Хөснетдинов – 11 тапкыр Россия, 5 тапкыр дөнья чемпионы. УШУны үз иткән 4 курс егетенең спорт белән дуслыгы нидән башланды икән?

# Нәрсә ул «хәрби сәнгать»?

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче



**– Ильяс, ни өчен нәкъ менә шушы спорт төрен сайладың?**

– Мин кечкенәдән үк каратэ белән шөгыльләнергә хыялландым. Әмма япон көрәшенә 6 яшьтән үк алмыйлар иде. Озак күңелсезләнергә туры килмәде, әнием бу мәсьәләне тиз хәл итте. Миңа бик яхшы укытучы – Фәрит Фазыл улы Галәвиевны табып бирде. Язмышыма шундый бүләге өчен бик рәхмәтлемен. Һәм менә инде 19 ел мин УШУ белән шөгыльләнәм. Ул кытай теленнән «хәрби сәнгать» дип тәрҗемә ителә. Шул дәвер эчендә байтак кына уңышларга ирештем, алга таба тагын да зурраклары булыр дип өметләнәм.

**– Дөнья күләмендә берничә тапкыр чемпион исеменә лаек булган кешегә бүгенге көндә белем ала торган Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты нинди дә булса яңалык бирә микән?**

– Институт миңа үзем сайлаган юнәлештә югары квалификацияле белгеч булып өлгерергә ярдәм итә. Әлбәттә, аның белән параллель рәвештә башка институтта, башка юнәлеш буенча да укырга була. Әмма мин үземне тулысы белән спортка багышларга телим һәм спортчы карьерасында гына тукталып калырга җыенмыйм. Алга таба үземнең дә балалар укытасым, спорт серләренә төшендерәсем килә.

**– Казанда спорт торышын ничек бәяләр идең?**

– Хәзер спорт белән шөгыльләнергә теләгән кешегә барлык мөмкинлекләр дә тудырылган. Универсиада объектлары тиз арада һәм бик сыйфатлы итеп төзелде, минем үземә дә шуларның берсендә шөгыльләнергә туры килде. Бу процесс кыска вакыт аралыгында башкарылгангадырмы, халык әле бу яңа дулкынга көйләнеп бетә алмый. Спортны пропагандалау җитеп бетми сыман. Шулай да, соңгы елларда спорт белән шөгыльләнүчеләр саны көннән-көн арта бара. Бу бик күңелле күренеш.

**– XXVII Бөтендөнья җәйге универсиада вакытында үз көчеңне сынап карау теләге юкмы?**

– Быел мин анда тамашачы буларак кына катнашачакмын, чөнки Халыкара олимпия уеннары комитеты УШУны җәйге олимпия уеннары исемлегенә кертү-кертмәү буенча карарны быел, 2013 елның көз аенда гына, кабул итәчәк. Уңай якка булыр, дип өметләнәм.

**Без дә шул теләктә калабыз һәм Ильяска алдагы көннәрдә дә зур җиңүләр телибез!**

### Белешмә

УШУ – Кытайда яшәп килә торган барлык сугыш сәнгатьләре төрләрен берләштергән атама. Аның төп максаты: сәламәтлекне ныгыту, тормышны озайту һәм үзоборона. Ушуның бик күп төрле стильләре һәм мәктәпләре бар. Кытайның һәр өязендә, хәтта авылында бу спорт төренең үз варианты бар. Кайбер мәгълүматларга караганда, барлыгы 130 стиль билгеле. Татарстанда Ушу – иң популяр спорт төре булып санала.

• Сәламәтлек

# «Зыянлы файда» синдромы

Табиб-киңәшче ролендә –
**Ләйсән ИСХАКОВА**

Һәр нәрсәнең үз уңай һәм тискәре яклары бар, дияргә яратабыз. Димәк, бик файдалы булып саналган шөгыль-предметлар да тискәре тәэсир ясарга мөмкин. Әнә шундый зыянлы «файда» очракларын бергәләп күзәтик.



**Йөгерү.** Күпләр йөгерүне төз фигураны сакларга ярдәм итә торган иң яхшы ысул дип саный. Хәтта бөек Гораций да: «Сәламәт чагында йөгермәсәң, авыргач йөгерергә туры киләчәк», – дигән. Бүгенге эре шәһәрләрне завод-фабрикалардан чыккан зарарлы газлар уратып алган. Шуңа шәһәр җирлегендә иртәнге йөгерү файдадан бигрәк зыян гына китерәчәк. Агулы һаваны эчкә йотканда, үпкәләр ярсый. Мондый чакта бронх астмасы эләктерү куркынычы аеруча зур. Иң яхшысы – спортзалдагы махсус йөгерү юлларында шөгыльләнү.



**Кояш.** Җәй җитү белән, күбебез кояш нурларында иркәләнер, кызыныр өчен пляжга ашыга. Инглиз галимнәре фикеренчә, кояш тәэсирендә зур күләмдә бүленеп чыга торган D витамины организмны йөрәк авырулары һәм шикәр диабеты башлану куркынычыннан саклый. Ләкин озак вакыт кояш астында тору башка чирләргә юл ача икән. Тәндә яман шеш барлыкка килү – шуларның берсе генә.



**Мунча.** Аның сәламәтлеккә уңай тәэсире медицина тарафыннан исбатланган. Мунчада матдәләр алмашы көчәя, сулыш һәм пульс ешая, кан йөреше тизләнә. Себерке белән чабыну исә мускуллардагы авыртуны бетерә, тәнне җиңеләйтә. Әмма шикәр диабеты, калкансыман биз авырулары белән интегүчеләргә эссе мунчада чабыну киңәш ителми. Тән температурасы гадәттәгедән югары, инфекция яки яман шеш авыруы булганда да чабынудан баш тартырга кирәк.



**Чыныгу.** Озак вакыт бу шөгыль профилактик медицина тарафыннан хупланды. Бу процесста иң мөһиме: организмны әкренләп температура тирбәнешләренә ияләштерү. Бернинди күнекмәләрсез бозлы суга сикерү яки кар өстеннән йөрү нәтиҗәсендә, бөерләр, нерв төеннәре шешәргә һәм хәтта инфаркт, инсульт очраклары да булырга мөмкин.



**Ризык.** Сәламәтлекне саклап калу өчен, безгә, спорт белән шөгыльләнү һәм начар гадәтләрдән баш тартудан тыш, нәрсә ашаганыбызны да күзәтү астында тоту мөһим. Баксаң, гап-гади помидор да теш эмаленҗимерә һәм өлкән яшьтәгеләргә аны ашау өчен бөтенләй киңәш ителми икән. Сөт продуктларын зур күләмдә куллану да файдалы түгел. Соңгы арада аеруча модага кереп киткән яшел чәйнең кан йөреше системасына уңай тәэсире турында күпләр белә. Нәтиҗәлелеге зуррак булсын өчен, аны көнгә 6-10 чынаяк эчүчеләр дә бар. Тик Нью-Джерси университеты тикшеренүчеләре яшел чәйнең бавыр һәм бөер авырулары китереп чыгарырга мөмкин икәнлеген исбатлаган. Сәламәт органнарга зыян салыр өчен, нибары 2 чынаяк яшел «сыеклык» та җитә икән.

Әлбәттә, табигать тәкъдим итә торган ризыклар файдалы. Әмма, организм таләп иткән күләмнән артыгын кулланган очракта, һәртөрле азык зыян гына салачак. Натураль продуктларны, төрлеләндереп, аз күләмдә ашарга кирәк. Алтын урталыкны табарга өйрәник!

DARELFONYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Битко салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.